Көлү – сихәт, көлеп яшәү мәслихәт!

ISSN 0136-7110

Чаян



САТИРА һӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ МАЙ • 2021 • КАЗАН

5



Вячеслав ШИЛОВ

Алмаз ХӘМЗИН

ШУЛ!..

Ялынмадым-нитмәдем,
Беркемнең дә кулын үпмәдем.
Тиешлесен үтәдем,
Күктән явар бәхет көтмәдем.

Ялвармадым сораныл,
Йөрмәдем дә хәтта зарланып.
Авырлыклар, каралып,
Килә торды җанга уралып.

Үтенмәдем Ходайдан,
Башы чыкмыйдыр дип, уйлаудан...
Мин генәме... болай да
Мохтаҗлар бит Аңа – муеннан!..

Сыкранмадым – сынганда,
Чыдамаслык яла яуганда,
Дуслар янда булганда,
Түзәсең лә икән моңа да.

Байрак иттем намусны,
Вөҗданымны һәм дә хакымны...
Сатмадым һич антымны,
Сакладым саф, гадел атымны!

– Дус түгел бу! – диделәр,
Арынуны кулай күрделәр,
Ләкин бездәй егетләр,
Бер мин генә әле түгелләр!

Әхлаксызлар дөньяда,
Шашып, талап гамәл кылганда,
Мәрхәмәтлек турында
Язып калыйм күңел тулганда.

Җаным, нигә тынмыйсың?..
Йөрәгем, ник даулап дулыйсың?..
Нихәтле дөрес булсам да –
Миңа язган язмыш – шул!

Ринат АБЗАЛОВ

БАБАЙЛАР

...Ленин бабай диеп тел ачылды,
Хрущев бабай, диеп үстек без.
Брежнев бабай өстә тәхет алгач,
Сталин атлысын да белдек без.

...Гомер бирде Ходай – күп хыяллар
Күз алдында туып, сулдылар.
Яңа хаким булган энекәшләр
Күптән инде бабай булдылар...

Бабайларны санап гомер үтте –
Озын авыр юллар уздык без.
Сизми калдык – киләчәкне көтеп,
Ак сакаллы булдык үзебез.

Нәрсә язган язмыш – кабул иттек:
Үпкәбез юк үткән елларга.
Теләк кала: тагын бер бабайның
Күкрәгенә иңеп еларга...

Михаил ЛАРИЧЕВ





ШОМБАЙ болай диде...

Хөрмәтле Чаян! Соңгы вакытта криминаль хәбәрләрдә хокук саклаучыларның исемнәре еш яңгырый. Йә судья ришвәт алганда каба, йә шук адвокат законсыз гамәл кылганда тотыла, йә суд приставы тоткарлана... Бу эшчәнлек өлкәсе бик хәвефлегә әйләнә бугай. Хокук саклау түгел, ә миналы кырны үтү диярсең...

В. ГАЯЗОВ

ЧИСТАЙ

Укучының хатын без Шомбай агабызга күрсәттек.

– Кайберәүләр кырда сөрми-чәчми, тир түкмичә генә елына берничә тапкыр мул уңыш җыеп алырга тели. Дөнья алай көйләнмәгән шул... – диде аксакал.

Вячеслав ШИЛОВ

ЮККА ӘЙТМӘСЛӘР...

Бер мәсьәләне хәл итү яңа мәсьәләләр тудыра.

Бер әйберне чистарту өчен, башка әйберне пычратырга кирәк.

Берәр нәрсә эзли башласаң, һәрвакыт эзләмәгән әйбер табыла.

Күршедәге чират тизрәк бара.

Әгәр тырнакларыңны киссәң, бер сәгатьтән нәрсә дә булса кырырга кирәк булачак.

Учакның кайсы ягына утырсаң да, төтен синең якка килә.

Теш һәрвакыт ял көненә каршы сызлый башлый.

Яхшы белгеч – кагыйдәләр буенча ялгышучы кеше.

Югалган әйбер актарган иң соңгы кесәдә табыла.

(Тормыш белгечләре мәҗлесендә язып алынды)





Александр ШУЛЬПИНОВ

Бетмәс вәхшәтлек

Борынгы Римны юк иткән вәхшиләр токымының кылган кара эшләре әлегә кадәр онытылмаган. Аларның каберләрен күптән тарих тузаны каплап киткән булса да, эшләрен дәвам итүчеләр хәзер дә җитәрлек. Бүгенге кабахәтләрнең мөмкинлекләре кимрәктер, әлбәттә, әмма ысуллары бик бай.

Хәзер вәхшиләр һөҗүменнән зыянны мәңгелек кала гына күрми. Франциядәге Тулузада билгесезләр зур чиркәүнең тышын буяп киткәннәр. Көнчыгыш Европада яшәүче элекке дусларыбыз даими рәвештә үзләрен фашизмнан азат иткән совет сугышчыларына куелган һәйкәлләрне мәсхәрәлиләр. Петербургта Садовая урамындагы атаклы су кызларына һич тынгы юк. Аларны йә буяу белән пычраталар, йә ватып китәләр. Ә Ленинград өлкәсендә атаклы Гайдай персонажларына – һәйкәлгә дә барып җиткәннәр. Гадәттәгечә, бу кыргыйлыкның сәбәпләре дә ачыкланмый, башкаручылары да билгесез кала...

Татарстан бөтендөнья шаукымнарыннан читтә калмый. Яшел Үзән районында җимерелгән мөселман зираты, Яңа Татар зиратында ватып ташланган кабер ташлары һәм Ташкирмән авылы янында киселгән христиан билгесе барыбызның да исендә...

Ә менә яңа мисал. Күптән түгел шул кара токым вәкилләре тарафыннан Чистайдагы "Хәзинә" бакчасы зыян күргән. Анда күренекле мәдәният эшлеклеләренең бюстларын кара буяу белән буяп чыкканнар. Нишләптер София Гобәйдуллинаныкына гына тимәгәннәр: сафларында авангард музыкасы сөюче булгандыр, күрәсең. Бу юлы гаепледәрне тиз тапканнар, алар җирле яшүсмерләр булып чыккан.

Март аенда Зәйдә азат итүче сугышчыга 6 метрлы өрянә һәйкәл янган. Янгынга каршы торучы махсус полимердан коелган сын ун елдан да ким торырга тиеш булмаган. Ләкин өлкәннәрнең җитди планнарын мәктәп укучылары җимергән: Мәңгелек ут өстендә чыршы ботакларыннан яккан учак ялкыны янмый торган материалга күчкән, һәм һәйкәлгә берничә минут эчендә ут капкан. Яшь вандаллар белән профилактик әңгәмә үткәрелгән, ә чиновникларга яшь буынның идеологик бушлыкта үсүләренә баш чайкыйсы гына калган.

Психологлар мондый нәрсәләрнең, гадәттә, яшь тинтәкләргә генә хас дип белдерәләр. Ләкин аңа карамастан, Мәскәү өлкәсендә, Пушкинодагы "Хәсрәтле ана" мемориалы янындагы мәңгелек утта йомырка кыздырып маташкан пенсионерканы тотканнар. Полициягә китергәч, ул чын күңеленнән аптырап утырган: нәрсә эшләгән соң ул шулхәтле? Тик әбекәйнең гаҗәпләнүе бернәрсә дә үзгәртмәс, ахры: аңа зур гына штраф яный...

Әмма вәхшилек белән штрафлар һәм әңгәмәләр белән генә көрәшмиләр икән. Мисал өчен, Белоруссиядә совет солдатларының каберләренә төкереп йөргән бер тинтәкне десантчылар... тәрбиягә алганнар. Яшь варварны тәрбияләүнең ысуллары әйтелми, ләкин аның бик тә үтемле булганын аңларга була. Һәрхәлдә, малай бик тиз гаебен танып, акылга утырган.

Ә нәрсә, бик тә шәп тәҗрибә! Армиябездә десантчылар җитәрлек. Әгәр инде патриотик тәрбияне мәктәпкә дә, гаиләгә дә ышанып тапшырып булмый икән, бәлки кыек юлга баса башлаучыларны чынлап та бер-ике атнага казармага озатыргадыр? Шулай итсәк, бәлки, аларның башланып килүче вәхшәтлек гадәтләре хроник формага күчмәс иде...

Людмила САФИУЛЛИНА



Ринат АБЗАЛОВ



Михаил ЛАРИЧЕВ



Вячеслав ШИЛОВ



Илдар НӘФИЕВ



• • •

Ир белән хатын аерылышалар.

– Сәбәбе нинди? – дип сорыйлар алардан.

– Көч кулланып, кыерсыту.

– Кем кемне кыйный соң?

– Кайчан ничек.

• • •

– Кызыкай, сезнең әниегезгә кияү кирәк түгелме?

– Юк, без әле элеккесенең дә миен ашап бетермәдек.

• • •

Ресторанда. Официант:

– Ханым, сезнең ирегез өстәл астында нишләп утыра?

– Ул минем ирем түгел. Минеке әнә ишектән кереп килә.

• • •

– Мин алты яшемнән үк фортепьянода уйнап акча эшли башладым.

– Концертлардамы?

– Юк, өйдә. Мин уйнамасын өчен, күрше көн саен акча түли иде.

• • •

– Ни өчен сез урманның тыелу зонасында затлы торак комплексы төзелешен туктата алмадыгыз?!

– Кулларым буш түгел иде, миңа күтәрмәслек чемодан китереп бирделәр.

• • •

Пластика хирургы йөзен яшәртергә теләүче ханымга аңлата:

– Әгәр дә таләпләрегезне үти алмасак, төп-төгәл кайтарып бирәчәкбез...

– Түләгән акчанымы?

– Юк, кыяфәтегезне!

• • •

Урам буйлап оныгы белән бабай бара. Карасалар, каршыларына укытучы килә. Бабасы – оныгына:

– Кач, тизрәк! Син бит бүген мәктәптә булмадың!

Оныгы:

– Син үзең кач. Мин сине үлем хәлендә ята, дидем.

• • •

– Чибәркәй, сез гороскоп буенча кем?

– Балык, ә сез?

– Балыкчы.

Михаил ФИЛОНОВ

ӨЙРӘНЕРГӘ СОҢ ТҮГЕЛ

Кемдер шалтыратты. Мин ишекне ачтым – алдымда затлы итеп киенгән чибәр егет басып тора иде. Ул нәфис куллары белән кара күзлеген салды һәм итагатьле итеп башын иде:

– Мин «Уңайлы йорт» идарәче компаниясеннән – көнкүреш коммуникацияләренең эшен күзәтү менеджеры! Сезнең чакыруыгыз буенча!

– Сантехникмы әллә? – дип сорадым гаҗәпләнеп.

– Төзексез техникагыз кайда? – дип сорады егет.

– Унитаз бачогыннан су агып тора, – дидем мин дулкынланып.

Ул кулларын аккош канаты кебек җәеп, бәдрәф ишеген ачып җибәрде һәм әмер бирде:

– Ачкыч һәм отвёртка!

Мин аптырап аңа карадым.

– Нәрсә? – дип гаҗәпләнде егет. – Өегездә ачкыч белән отвёртка юкмыни? Исең китәр!

– Бар, бар! – дип мыгырдадым мин һәм иремнең инструментлар тартмасын китердем. – Менә, мәгез! – һәм аңа сораган әйберләрен тоттырдым.

Аның күрсәтмәләренә буйсынып, бачокның капкачын алып куйдым. Бераз каранып торганнан соң ул соңгы мода буенча алынган чәчен сыйпап куйды:

– Ничек уйлыйсыз, ул нигә ага икән?

– Белмим шул, – дидем мин.

– Ә сез яхшылап уйлап карагыз!

– Бәлки, эш прокладкададыр?

– Нәкъ өстенә бастыгыз! – дип шатланып куйды сантехник. – Бу очракта нишләргә кирәк инде?

– Алыштырыргадыр, – дидем мин шикләнеп кенә. – Ләкин... бәлки... сез...

– Ханым, – дип өзде ул мине. – Бу сезнең бачокмы, әллә минекеме? Запас прокладкагыз бармы?

– Юк бугай шул, – дидем мин, кызарып. – Шулай да...

Инструментлар тартмасында актарынып, резин түгәрәк тартып чыгардым.

– Бумы?

– Охшаган бугай... – диде сантехник, кашын җыерып. – Ә хәзер эшкә тотынабыз!

Ул җентекләп прокладка алыштыруның нечкәлекләрен аңлатты. Гаҗәеп хәл: мин бу эшне бик өлгер башкардым, ул мине хәтта мактап та куйды.

– Котлыйм! – диде ул, эш тәмамлангач. – Ә хәзер су җибәреп карагыз! Эшегезне тикшереп карыйк!

Бачок сәгать кебек эшли иде.

– Чакырту һәм киңәшләр өчен – биш йөз сум! – диде сантехник, галстугын төзәтеп.

Мин егеткә җиде йөз сум чыгарып бирдем. Артыгын түләү җәл түгел иде. Ни дисәң дә, унитаз бачогының прокладкасын алыштырырга өйрәндем бит, ә моның өчен түләргә кирәк! Аның каравы, хәзер бу эшне күземне йомган килеш тә башкара алам. Бернинди чибәр сантехниклар да кирәкми...

Валерий ТАРАСЕНКО



Виктор ФЁДОРОВ





Александр ШУЛЬПИНОВ





Алмаз ГЫЙМАДИЕВ

ЮЛӘРЛӘР АВЫЛЫ

Бу вакыйга моннан 37 ел элек бер татар авылында булды. Ул вакытта әле компьютерлар да, интернет, смартфоннар да юк иде. Советлар Союзы дигән бөек ил дә таркалмаган иде әле. Ачуланмагыз, районын да, авылын да әйтә алмыйм – үпкәләячәкләр...

Колхоз рәисе Габбас санаторийга киткәч башланды хәлләр. Үз урынына ул парторг Вәдүтне калдырды. Шуны гына көткән диярсең, иртәгесен үк клубта җыелыш җыйды Вәдүт.

– Күңелсез яшибез, җәмәгать, – диде парторг, графиннан стаканга су агызып эчкәч. – Дөрес яшәмибез. Аралашмыйбыз... Йөрешмибез... Бер-беребезнең шатлыгын, кайгысын дигәндәй, уртаклашмыйбыз...

– Нәрсә предлагаешь? Конкретно әйт! – дип кычкырды арткы рәтләрдән берәү.

Вәдүтнең тәкъдиме бик тә сәер иде.

– Кибет каршындагы белдерүләр тактасын хәтерлисезме? – диде ул күзләрен кыса төшеп. – Менә шул тактада һәр авылдашыбызның тормыш-көнкүреше ярылып ятса иде...

– Как это? – диде гел урыс сүзләре кыстырып сөйләргә яратучы плотник Садри.

– А вот так: фотограф Шәяхмәт һәрберегезгә кереп, өегездәге кызыкларны фотога төшерәчәк! Шуларны көн саен тактага элә барачакбыз! – Вәдүтнең күзләре ялтырый иде. – Күңелле булачак, җәмәгать! Аралашу булачак! Шәяхмәтне буш итмәбез, контор хисабыннан түләрбез...

Парторгның мондый сәер тәкъдиме күпләрнең башына барып җитмәде.

– Аралашу булмый бит инде бу, – диде берсе кыюсыз гына. – Сурәт карау гына була...

– Ә без тактага ак кәгазь һәм шунда ук җепкә тагылган ручка куярбыз, – диде Вәдүт тантаналы итеп. – һәрберегез фотоларга карата фикерләрен яза алачак!

...Аптырашып, сәерсенеп кенә таралыштылар. Вәдүтне хуплаучылар да, тиләгә чыгаручылар да "Габбас югында эш күрсәткән була инде" диючеләр дә табылды.

Икенче көнне эчәргә һәм урысчарак сөйләшергә яратканы өчен "сто грамм" кушаматына ия булган плотник Садри белдерүләр тактасын зурайтып эшләп куйды.

Беренче фото озак көттермәде. Түбән оч Зарифә ял көне үпкә-бавыр пәрәмәче пешергән булган. Шәяхмәт шуларны фотога төшереп, тактаның иң өске өлешенә элеп куйды. Пәрәмәчләр белән беррәттән Зарифәнең кып-кызыл бите дә кадргa эләккән иде. Ике сәгать тә үтмәде, кибеткә ипи алырга килгән фельдшер Нәсимә фото астына "Ням-ням" дип язып китте. Кемдер берәү "Тәмлеее..." дип өстәде. Ошый башлады бу нәрсә авыл халкына. Икенче көнне тактада завклуб Ландышның шактый кабара башлаган корсагын тотып төшкән фотосы пәйда булды. "Җиденче бәбиебезне көтәбез..." дигән сүзләре дә бар иде. "Сөбханалла!" дип язып куйды берсе. "Бәхете белән тусын сабый..." дип өстәде икенчесе. Усал телләр дә табылды. Берәү "совет хатынына болай фотога төшү килешми" дисә, тәнлә бер хәерсезе "монысы кемнән инде тагын..." дип язып киткән иде...

Әлеге олы эштән мәктәп хезмәткәрләре дә читтә калмады. Ирле-хатынлы укытучылар – Айзат белән Фазлыяның да зур кәрзин тотып төшкән фотолары тактага менеп кунаклады. Кәрзиннән ниндидер үләннәр күренеп тора, фото астына "очсыз бәядән мәтрүшкә сатабыз" дип язылган иде.

(Ахыры киләсе санда)



• • •

Авыл. Ике хатын кычкырыша:

– Синең кәҗәң безнең бакчадагы бөтен кәбестәне ашап бетергән!

– Һай, харап булган икән! Ә менә синең тавыкларың йомыркаларын безнең печәнлеккә менеп сала. Мин әйтмим, түзәм бит әле.


• • •

Безнең халык – иң хезмәт сөючән халык! Атна буе тир түккәннән соң, ул гына көрәк тотып бакчада ял итә.

Ринат АБЗАЛОВ



Игорь КИЙКО



Валерий ТАРАСЕНКО



Антон МАКУНИ

Җанга тигән сүзләр

Электричкада бару күңелсез булмасын өчен, дача буенча күршеләр Хәмит белән Вахит кроссворд газите сатып алдылар, һәм тәрәзә янында урнашып, кроссворд чишә башладылар.

– Тә-әк, – диде Хәмит, – башладык: биш хәреф «шар формасы алырга омтылучы сыекча»?

– Сарай! – дип ярып салды Вахит.

– Нинди сарай? – диде Хәмит. – Тамчы бу, тамчы! – һәм ул сүзне шакмакларга язып куйды.

– Буйга өченче, – дип дәвам итте Хәмит. – «йорт хайваны», дүрт хәреф?

– Сарай! – дип тавыш бирде Вахит.

– Тагын нинди «сарай» инде ул?! – дип дулый башлады Хәмит. – Мәче бу, аңладыңмы? Тә-ә-әк... Биш хәреф, аркылыга уникенче, – «сыра эчәргә шәп кабымлык»?

– Сарай! – дип кулын болгады Вахит.

– Балык бу, балык!!! – дип кычкырды Хәмит. – Теңкәгә тидең бит сараең белән!

– Нишлисең бит, – дип тирән сулап куйды Вахит. – Дачада сараем бөтенләй череп бетте... Гел шуның турында гына уйлыйм. Рәтләргә ярдәм итәрсең бит?

Хәмит җавап бирмәде, ул кроссворд белән мәшгуль иде:

– Буйга унҗиденче – «җирне бүлеп торучы корылма», биш хәреф, – Хәмит Вахитка тагын бер мәсьәлә куйды.

– Сарай! – дип кычкырды Вахит бөтен вагонга, – сарай, дөмегеп киткере!!!

– Сарай? – дип сорады Хәмит. – Нинди сарай булсын, койма ич! – һәм ул шакмакларны тутырып куйды.

Кинәт кенә нәрсәдер исенә төшереп, Хәмит күңелсезләнеп китте һәм газитне читкә куйды:

– Ярар, ярдәм итәрмен сараеңны рәтләргә, тик син дә минем койманы тәртипкә китерергә булышырсың инде!..



КЕРЕМЛЕ ИНВАЛИДЛЫК

Түбән Каманың 41 нче номерлы медик-социаль экспертиза бюросы җитәкчесе инвалидлык белән сату итүдә капкан. Тикшерүчеләр фикеренчә, мондый кәгазь өчен бер елга 15 мең, ә вакыты чикләнмәгән очракта 50–65 мең сум түләргә туры килгән. Клиентлар арасында РФның Түбән Кама пенсия фонды бүлекчәсенең элекке егерме ике хезмәткәрләре табылган. Инвалидлык бирүнең сәбәпләре күптөрле дип атарлык булмаган – барча клиентларга да "каты формадагы саңгыраулык" диагнозы куелган.

АСТЫРТЫН ДИРЕКТОР

Казанда коллекторлык фирмасы директоры судка тартылган. Аны бурычлар өчен хөкем итәчәкләр. Аның үзе эшләгән оешмага күп кенә бурычлары булуы ачыкланган. Җитәкчегә карата барлыгы 100 мең сумлык дүрт процессуаль гамәл кузгатылган. Өстәвенә, астыртын директорны штраф һәм эшеннән алу көтә.

ХӘВЕФЛЕ РЕЙСЛАР

Иҗтимагый транспорт халыкны авария очраклары белән куркытудан туктамый. Бу юлы ЮХИДИ маршрут автобусларына игътибар итәргә булган. Һәм юкка түгел – быел гына алар катнашы белән өч дистәдән артык авария очрагы булганы ачыкланган. Инспекторлар 8 мең тапкыр кагыйдә бозуга чик куйганнар. Мең тапкырдан артык төзексез машиналарны кире паркка борганнар. Җиде тапкыр руль артында йөртү хокукы булмаган кешеләр тотылган. Ә берсенең таныклыгы булса да, үзе нык кына "салмыш" булып чыккан.

ВАКСЫНМАСКА БУЛГАН

Казанда бер каракны алтынчы тапкыр бер үк көнкүреш техникасы кибетендә урлаган чагында тоткарлаганнар. Моңа кадәр егет вак әйберләр генә алып чна торган булган, шуңа күрә югалту соңыннан гына ачыкланган. Үзенең үткенлегенә ышанып беткәч, ул вакланып торуны кирәк тапмаган һәм 27 меңлек компьютерны эләктергән. Ләкин йөк җиңелдән булмаган, һәм "даими клиент" товары белән бергә полиция кулына эләккән.

Гүзәл НӘБИУЛЛИНА

Җаен тапты

Хәбиб язу өстәле янында бик озак утырды. Алдында кәгазь белән каләм. Тик менә ничә сәгать инде анда берни язылмаган иде.

– Нишләп утырасың анда вакыт уздырып? – дип кызыксынды хатыны. – Ичмасам, ял көне өй эшләрендә ярдәм итәрсең дип өметләнгән идем.

– Әй, хатын, син берни аңламыйсың ла. Менә хәзер кемгә карама – язучылыкка тотынды. Мин алардан ким түгел ләбаса!

– Соң, син нәрсә турында язмакчы буласың инде, ничә еллар буе циркта эшләп: маймыллар, филләр артыннан чүп җыеп йөргәнеңнеме?

– Юк шул, җаныем, мин шундый мәкалә язам, шундый!..

– Нинди? – дип көлемсерәп куйды хатыны.

– Үзең дә шаклар катарсың әле.

Хатыны, берни дәшмичә, кер юарга тотынды.

Хәбиб, башына уй кермәгәч, малаеның бүлмәсенә керде.

– Ничек, улым, укулар барамы? Әдәбияттан нәрсәләр үтәсез?

– Элек бер дә ишетелмәгән язучының әсәрләрен укыйбыз. Нәрсә язганы да аңлашылып бетми шунда...

– Кая, ниләр язалар икән, – дип кызыксынды атасы.

Карап чыккач, аның башына бер уй килде.

– Хәзер язучылар күп. Кем, нәрсә язганын күзәтеп бетерүче дә юк. Шулар арасыннан мин дә үземә яраклы нәрсә таба алмаммы икән?

– Улым, син миңа бу китабыңны биреп тор әле, – диде дә Хәбиб, үз бүлмәсенә кереп китте.

– Тә-ә-к, нәрсәдән башлыйм икән соң? Әһә, менә моннан берничә җөмлә алырга була... Менә, болары да ярап тора. Әй, мин бу китаптагы язучыларның барлы-юклы фикерләрен йолкып, бер әсәр язып чыгара алам бит...

Кич җиткәндә, Хәбибнең өстәлендә кыска гына язма ята иде.

– Мә, хатын, укы! – дип, горурланып кәгазь битләрен күрсәтте ул хатынына.

Тегесе укып чыкты да:

– Бер дә син болай яза беләсең дип уйламаган идем. Булдырасың икән бит!

– Утыргач, уйлагач була инде ул, – дип, улына карап, серле генә елмаеп куйды Хәбиб.

Аннары аны аерым чакырып:

– Улым, синең тагын нинди китапларың бар? Карап чыгыйм әле. Кем белә, бәлки кирәге чыгып куяр...

– Әй, әти! Китап актарып утырганчы, син интернетка кер. Андагы материал!.. Күңелең нәрсә тели, шуны таба аласың. Мин дәресләргә дә шуннан гына әзерләнәм. Вакыт уздырып, баш ватып утырмыйм.

– Ну, улым, маладис та үзең, маңгаең киң икән! Җаен табып бирдең бит. Болай булгач, вак-төяк белән маташмам. Иртәгә үк романга тотынам!

Валерий ТАРАСЕНКО



• • •

Бер җитмеш яше тулган бай яшь кызга өйләнә. Һәм бу турыда күптәнге дустына хәбәр итә. «Мин, әлбәттә, балам булыр дип өметләнмим инде», – дип өсти ул ахырда.

Дустыннан җавап килә: «Син, әлбәттә, өметләнә алмыйсың, ләкин хатыныңның көтмәгәндә бала табуына әзер булырга тиешсең».

Александр АЛЁШИН





Дамир МОРТАЗИН

ЯҢА ПИГМАЛИОН

Беренче очрашуда ук хатын-кызларда камиллек эзләгәнен белдерде ул, ә мин моның өчен аңа туры килә торган чиктән тыш идеал икәнмен. Шул сүзләреннән соң гашыйк булып куйдым бит шуңа.

Бервакыт, шашып-шашып үбешкәч, ул миннән ягымлы итеп сорап куйды.

– Сөеклем, синең иреннәреңә бераз гына кабарынкылык өстәргә кирәк. Операция сине искиткеч гүзәл итәр...

Мин ризалаштым, чөнки ул миңа абруйлы бик ышаныч казанган клиника адресын әйтте. Иренемне кабарттырыбрак җибәрү – кварталга бер бирелә торган премиямне йотты, ниләр генә эшләмәссең яраткан кешең өчен.

Тиздән ул миңа, сынчы үзенең ясалып бетмәгән иҗатына карап торгандай итте дә:

– Начар түгел, начар түгел... Менә хәзхер бераз гына борыныңны төзәтеп җибәрергә кирәк. Ул синең яңа иреннәреңә туры килми. Чүт кенә бөкрәйтеп куйсак, битеңә кабатланмас ямь өсталер иде... – диде.

Мин кабат шул ук клиникадагы хирург пычагы астына ятып, борынымны рәткә китердем, моңа инде ял итүгә әзерләп куйган бөтен акчам кереп бетте.

– Менә шәп булган! – диде минем сөеклем. – Тагын... – аның таләпчән карашы ияк астымнан икенче номерлы күкрәк өемчегенә төште.

Шундук аңладым – кеше миндә чынлап та идеал күрергә тели. Икенче номерлы белән генә нинди идеал буласың инде?

Клиникада ике ай чамасы ятканнан соң, мин аңа үземнең яңа бюстымны тәкъдим итү кичәсе ясадым. Ә бит бу үзгәреш минем бөтен җыйган акчаларымнан колак кактырды.

– Вау! – дип заманча шаккаткан булды ул. – Син – могҗиза! Әйләнгәләп ал әле – бөтерел!..

Ул мине тикшерергә керешә, әйтерсең – Пигмалион Галатеяне.

– Әй-бә-ә-т... – диде ул бәяләп. – Өске өлеш белән бетердек. Хәзер аскысын карыйбыз. Монысы соңгысы булачак – Бразилиядәгедәй камиллек!

Моның өчен миңа банктан кредит алырга туры килде. Матурлык корбаннар сорый, ә камиллек эзләү – акча.

Клиникадан чыгуга ук мин Пигмалионыма шалтыраттым. Үземнең аскы формамны күрсәтергә кирәк бит инде. Ләкин аның телефоны нигәдер җавап бирми, кайда яшәгәнен дә сорамаган идем. Пластик операцияләр ясап йөргәндә без миндә очраша идек.

Минем силикон күкрәгем суынды, ә үземнең бишенче җирем һәм күңелем нидер сизә – хатын-кыз чутеки, Бразилия формасы да ул гадәтен онытмаган. Соңыннан аңладым: минем Пигмалион, ышанычлы дәваханәләргә, процент исәбенә, минем кебек клиентлар ташып торган. Әйттеләр: минем белән мәхәббәт куерткannan соң ул, инде ниһаять, фатир алырлык акча туплап җылы якларга ычкынган, хәзер анда да яңа Галатеяләр эзлидер.



Александр ШУЛЬПИНОВ

СҮЗ ИЯРӘ СҮЗ

- Хастаханәгә эләккәнсең икән, исеңдә тот: иң мөһиме – дәвалана башлаганчы ук терелеп чыгарга тырышу.
- Яңа диагноз барлыкка килде: симптомсыз авыру. Элек алар сәламәт дип аталалар иде.
- Гомереңнең беренче яртысын сәламәтлегең синең өчен эшли, икенче яртысын – син аның өчен.
- Кайберәүләр һәр көн иртән башларын төзәтә-төзәтә башларын югалталар..



Илдар НӘФИЕВ



Абау!

ЭРОТИК ПОДТЕКСТ БЕЛӘН

Мәскәү Арбитраж суды судьясы Екатерина Игнатованың суд карарлары текстларында очраклы рәвештә яшерен сүгенү сүзләре тапкан. Сүзләр ак шрифт белән җыелган була һәм курсор белән каралткач кына күренгән. Укучыга эротик характердагы гамәлләр кылу тәкъдим ителгән. Мондый әдәпсез сүзләр биш хөкем карарында табылган. Суд карарларын ирекле интерпретацияләүдә гаепләләр табылган һәм эштән азат ителгән.

РИТУАЛЬ ЯНАУ

Брянскида мәрхүмнәрнең гәүдәләрен биргән өчен акча таләп иткән патологоанатомнарны тоткарлаганнар. Табиблар мәрхүмнәрнең туганнарының эмоциональ халәтен һәм матди мөмкинлекләрен белеп, процедураны тизләтү өчен 3 тән алып 12 мең сумга кадәр акча таләп иткәннәр. Ике ай эчендә алар, 80 кешене алдалап, 400 мең сум күләмендә акча алганнар. Группировкага барлыгы 11 патологоанатом һәм 7 ритуал хезмәт күрсәтүче кергән.

ЗАКОНЛЫ БОРЩ

Украинаның танылган оста пешекчеләрнең берсе – Евгений Клопотенко украиннарга үз-үзләрен халык буларак эзләү процессында милли кухняны декоммунизацияләргә кирәк, дип белдергән. Ә моны салымнар һәм җыю системасы ярдәмендә эшләргә була. Әйтик, пешекче совет чорының азык-төлек традицияләрен сакларга теләүчеләрне акчалата җәза бирергә тәкъдим итә. Шуның белән бергә ул илнең мондый карарлары өчен кирәкле сәяси ихтыяры булмавын аңлый, шуңа күрә аңа «борщны» әйләндерергә кала.

ЮГАРЫ ТОННАРДА

Пермь краенда ике депутат ярышырга исәпли. Шунысы гаҗәп: урамнарны сыйфатсыз җыештыру була сәбәбе. Добрянка шәһәре депутаты Марк Коробов үзенең коллегасы һәм коммуналь предприятие директоры Сергей Федорецка кисәтү ясый. Аргументланган җавап урынына Федорец Коробовка һөҗүм итә. Үзенең аклавында коммунальщик сугышның булмавын, ә югары тоннарда сөйләшүен һәм зур булмаган бәрелеш булуын белдерә. Принципиаль конфликтны полиция тикшерәчәк.



Василий АЛЕКСАНДРОВ


Валерий ТАРАСЕНКО



Виктор ФЁДОРОВ

Мирзаһит тормышыннан

САКЛАП КАЛА АЛМАДЫК!

Басыйра карап торырга болай начар кеше түгел иде. Кыек юлга басканы булмады. Берүзе хуҗалыкны алып барды. Берүзе, ирсез, кызын карап үстерде. Дөрес, усал телләр аның турында "мәзәгрәк ул" дип әйтәләр иде кайчакта. Алай дисәң, кайсыбыз мәзәк түгел соң?

Еллар үтте, кызы Рания мәктәпне бетереп шәһәргә күчеп китте. Берзаман ул әнисе белән таныштырырга бер егет ияртеп кайтты. "Филолог", – дип пышылдады ул әнисенең колагына, икесе генә калгач.

Басыйра бәлеш пешерде, гөжләтеп самавыр куйды – кызының егетенә бик тә ошыйсы килә иде аның. Чынаякларны хуш исле чәй белән тутырып, егетнең савытына тулы өч кашык шикәр салды һәм болгатып ук куйды. Тик егет, бер йотым ясау белән, аны идәнгә төкерде. Филологның күзләреннән яшь бәреп чыкты. Басыйра, дулкынланып китеп, шикәр урынына тоз салган икән. Егет, учы белән авызын тотып, ишегалдына чыгып йөгерде. Шуннан соң ул авылда беркайчан да күренмәде.

– Шагыйрь күңеле нечкә инде ул... – дип аңлатты соңыннан бу хәлне Рания.

Икенче егеткә Басыйра шундый кызу итеп мунча якты ки, ул аңын югалтып, тора алмыйча ятты. Өченчесе шул ук мунчада таеп егылып, башын тишеп кайтты.

Рания чираттагы кияве – бизнесмен кайтачагын хәбәр иткәч, күрше-күлән җыелышып киңәшмә уздырды.

– Битарафлыктан арынып, ярдәм итәргә кирәк! – диде Вәли. – Болай булса Раниябез кызлыкта утырып калачак!

Бу юлы Басыйра тагын берәр мөгез чыгармасын өчен, бөтен эшне үзара бүлергә булдылар: Вәли ишегалдын тәртипкә китерде, Мирзаһит мунча якты, Оркыя чәй әзерләде, ә Рания идәннәрне юып чыкты.

Менә авылга өр-яңа джипта бизнесмен килеп төште. Бөтенесе дә план буенча барды: Басыйра ишегалдында кунакны каршы алды, аннан соң гөбәдия белән чәй эчтеләр, ә кичке аштан соң эшмәкәр мунчага китте.

– Мунча менә диген булды, апа! – диде ул, алсуланган йөз белән кайтып кергәч.

«Булды, эшләр җайга салынды», – дип уйлады күршеләр, һәм өйләренә таралышты.

Төнлә ишеп кар яуды. Кадерле кунакның машинасы белән бергә бөтен ишегалдын басып китте. Беркемне дә уятмыйча гына Басыйра торып самавыр куйды. Аннан соң тышка чыгып кулына көрәк алды һәм кунакның машинасын кардан арындырырга тотынды.

Тиздән бизнесмен килеп чыкты. Джип янына килеп, аны як-яктан карап чыкты. Ялтыравыклы кара өслектә тимер көрәк тырнаган эзләр чәчрәп тора иде. Егет Басыйрага сәерсенеп карады да, берни әйтмичә, машинасына утырып китеп барды. Рания чыгуга күршеләр инде җыелып өлгергәннәр иде.

– Саклап кала алмадык! – диде тирән сулап Мирзаһит.

Эшнең нәрсәдә икәнен белгәч, кыз берьюлы көлде дә, елады да. Ә бер елдан Рания бернәрсәгә дә исе китми торган егет очратып, шул елны ук аңа кияүгә чыкты.

Зөлфәт ШАҺИӘХМӘТОВ



Анатолий НЫРОВ

Амур ФӘЛӘХ КЫТЫКЛАРЫ

АМУР АШЫЙ АНЫ

Җәмәгатем Фәүзия Экология министрлыгында эшли. Тикшерү белән Актаныш якларына барып чыга болар. Эшләрен төгәлләгәннән соң Актаныштa бер йортка тукталалар. Хуҗабикә кунакларны кыстый-кыстый сыйларга керешә. Өстәл тәм-томнан сыгылып тора. Ризыкларыннан авыз итми калсаң хуҗабикә үпкәләргә мөмкин дип, кунаклар, тамаклары ачыкмаган булса да, тегене-моны капкалап утыралар. Хуҗабикә төрледән-төрле ризыкны чыгарып кына тора. Ниһаять, кыенсынып кына булса да кунакларның берсе:

– Апа, зинһар, ташымагыз инде шулкадәр ризык, безгә чәй булгач җиткән, – ди. – Ашап бетереп булмый бит, аларын кая куярсың?

– Аптырамагыз, балалар, әрәм булмас, Амур ашар әле...

Фәүзия, "колагым дөрес ишеттеме?" дигән кебек, аптырап кала.

– Карале, минем иремне монда да беләләр икән бит, – дип пышылдый ул янәшәсендә утыручы хезмәттәшенә. – Әллә калган ризыкларны миңа төяп җибәрмәкчеләр инде?

Яхшымы, начармы – минем чынлыкта да шундый гадәтем бар: тәмле ризык булганда, әрәм итмим әле дип, җәмәгатем белән улымнан калганнарны ашаштыргалыйм.

Ә хуҗабикәнең эте "Амур" кушаматлы икән...

ДӨРЕС ЯЗАМ БУГАЙ БИТ...

Казан дәүләт университетында 3 нче курста укып йөргән чак. Гарәп теле дәресе бара. Укытучы Лена апа Таҗиева тактага гарәпчә ниндидер сүзләр яза. Без, студентлар, дәфтәрләрне шытыр-шытыр китереп, ул язганны күчерәбез.

Күршем Вил Хәсәншин минем дәфтәргә күз төшергән икән. Кинәт колак төбендә генә калын тавышы ишетелде:

– Нәрсә язасың син анда, тиле?

Вилнең кычкырып әйткән сүзләреннән мин генә түгел, Лена апа да сискәнеп китте. Язуыннан туктап, бер адым чигенде дә, берара тактага төбәлеп торды һәм:

– Юк ла, дөрес язам бугай бит, – дип куйды...

"ПРОМОКАШКА"

Университетта укыган еллар. Сессия. Логика фәненнән имтихан көне килеп җитте. Аңа әзерләнү өчен бердәнбер байлык – калын дәреслек. Тырыш, үҗәт студентлар иренмичә "бомба", "шпаргалка" әзерли. Ялкаураклар теге китапны гына кыстырып керергә ниятли...

Имтихан бара, аудиториядәге тынлыкны бер чебен безелдәгән тавыш кына боза. Менә бервакыт Илдар исемле студент теге калын китапны кулыннан ычкындырып җибәрде. Аудитория дер селкенеп куйды. Студентлар куркып, сагаеп калды. Барыбызның да карашы Комаров фамилияле укытучыда.

Комаров, каш астыннан гына карап, гаеплене эзләп тапты да:

– Нәрсә булды ул? – дип сорап куйды.

– Промокашка! – диде Илдар уйлап та тормыйча.

Аудитория шаркылдап көлгән тавышка күмелде.

– Зачеткаңны бир! Зирәклегең өчен "5"ле!

Иң кызыгы шунда: моңа кадәр үтә кырыс укытучылар исәбендә йөргән Комаров Илдар Мифтаховка, чыннан да, "5" ле куеп чыгарды...



Эрнест ДЫШАЕВ, «Чаян» № 11, 1989

– Бөтен булган нәрсәмне – сабын, шампунь һәм теш щёткамны оныгыма калдырам!



Суфия НАСЫРОВА, «Чаян» № 18, 1978

– Әни, әкият сөйлә әле!
– Хәзер әтиең кайткач сөйләр.



• • •

– Доктор, ә түләүле операция бик кирәкме?

– Әлбәттә, кирәк. Ул операцияне ясамасак, Альп тауларында чаңгыда шуу мөмкинлеге булмаячак бит.

– Миңа бит чаңгысы да, таулары да кирәкми.

– Кугәрченем, сүз бит сезнең турыда бармый.

• • •

– Директор әфәнде, мине кайчан ялга җибәрәсез инде?

– Ял, ял... Азды хәзер халык. Җәй буе тәрәзә янында саф һава сулап утырасың бит инде. Тагын нәрсә җитми сиңа?

• • •

Барлык хатыннар да кияүгә яхшы ирләргә чыга, ә кабахәтләре белән аерылышалар. Сорау: яхшыдан кабахәткә әверелерлек нинди этлек эшлисез соң сез аларга?

• • •

Бай булу өчен зур хезмәт хакы алып эшләү түгел, ә хезмәткәрләргә аз түләү уңайрак.

• • •

Иренең балыкка барырга җыенуын күреп, хатыны кызып китә:

– Нәрсәсен яратасың соң син шул балыкның?

– Сөйләшмәвен! – ди ире.

• • •

– Кирәк бит! Әле күптән түгел генә йомырка 50 тәңкә тора иде, ә хәзер инде 70!

– Әйдәгез минем белән, гражданин!

– Бу бит дөрес! Нигә мин сезнең белән барырга тиеш?!

– Законсыз мәгърифәтчелек белән шөгыльләнгән өчен.

• • •

Акция! Бакчамда, бушка, балык тотар өчен яңгыр суалчаннары казып алырга рөхсәт итәм... Ашыгыгыз! Тәкъдим итү чикле – 4 кенә сутый калды!

• • •

Төнлә теш табибының фатирына талаучы керә һәм аннан акча таләп итә.

– Кызганычка каршы, – ди табиб, – хәзер өйдә акчам юк шул. Ләкин болай гына чыгып китәргә теләмәсәң, бушлай тешеңне алдырырга була.

Сергей АНДРИАНОВ



Василий АЛЕКСАНДРОВ





ЧАГЫШТЫРМАЧА ШАРТЛАР

Кадерле "Чаян"! Бала тудыру йортында, әниләрнең еш кына мондагы шартларга зарлануларын ишеткәч, мыскыллы рәвештә болай дип җавап биргәннәр: "Әле элек басуларда эшләгәндә тудырганнар, бер дә зарланмаганнар!" Болай итеп, кемнәр Әлмәттәге бала тудыру йортында булмаган, шулар әйтә. Андагы шартлар басудагы кебек үк түгел дә, ләкин шулайрак.

Бу йорт нефтьчеләр башкаласында инде күптән капиталь ремонтка мохтаҗлык кичерә. Диварлары кыршылып беткән, шыгырдап ачыла торган ишекләр, җилләтү өчен генә булса да ачылмаслык тәрәзәләр, бердәнбер душ, бөтен коридорга бер бәдрәф – чиратның очы-кырые юк. Бигрәк тә ятаклар кот очарлык хәлдә – басудагы җир йомшаграктыр, мөгаен. Ә урын-җир кирәк-яраклары әллә нинди төсләргә кереп беткән. Тудыручыларга чисталык өчен пелёнкалар бирәләр, әмма аны да җәлләп кенә. Зарланудан файда юк – рәсми рәвештә җавап бирәләр – барысы да санитар нормаларга туры килә, дип. Инфекция юкмы? Юк. Шул ярамаганмы?.. Әни бәхетен бернәрсә дә каралта алмый. Ләкин җитешсезлекләргә күз төшереп, күңел бозу мәңге истә калачак...

А. КАМАЛИЕВА

әлмәт

ЮЛ КЫРЫЕНДА

Хөрмәтле редакция! "Беседа" торак комплексыннан фатир сатып алганда төзүчеләр безне матур, уңайлы урынга әләгүебез белән шатландырдылар. Чыннан да, мәктәп, балалар бакчасы, даваханә, кибетләр – барысы да янәшә әлеге Дәрвишләр бистәсендә. Аралар ерак түгел, җәяү дә барып була. Ләкин бу цивилизация рәхәтлекләренә әләгү өчен пычрак һәм куркыныч юл кырыйларыннан исән калып үтү бик шикле. Дөрес, әле күптән түгел "Беседа"да автобус тукталышларын әйбәтләп эшләделәр, анда алты маршрут автобуслары рәхәтләнеп туктый ала. Ләкин аларның йөртүчеләре бик туктап тормый, сәбәбе – тукталышларны дөрес урнаштырмаганнар һәм инде законлаштырып та булмый икән, ни дисәң, акчалары юк. Шуның өчен трасса буйлап җәяүлеләр өчен Дәрвиш бистәсенә һәм Нагорныйга хәтле сукмак түшәделәр. Ләкин безне монда да уңышсызлык көтеп торган. Бу сукмак төшкән җир, ягъни тротуар, Гослесфонныкы икән һәм анда рөхсәтсез эш башкару тыела. Нәрсә килеп чыга – "Эше бетте, кодагый!.." Түрәләр иң өсләрен селкетә, төзүчеләр бернәрсә белән дә ярдәм итә алмый, ә без – яшәүчеләр, юл кырыенда калып, уйлыйбыз: "Тагын кайда барып теләник икән?.."

"Беседа" торак комплексы халкы.



Михаил ЛАРИЧЕВ



Александр АЛЁШИН

Ир-атның өй җыештыруы, гадәттә, кирәк әйберен эзләп тапканнан соң, тәмамлана...

#СҮЗЕҢ - КИТАП
@kitap_fm



РЕКЛАМА



Гамил Афзал – егерменче гасырның татар шигъриятендә иң күренекле шәхесләрнең берсе. Ул – лирикада, юмор һәм сатирада Тукай традицияләрен дәвам иткән шагыйрь. "Тукайчылык – Гамил Афзал иҗатының рухында. Рухы аның шигырьләренә сибелгән. Тукайдан күчкән иң әйбәт сыйфат – дөреслек, туграшык, иман", – дип язган аның турында Сибгат Хәким.

Гамил Афзал – татар, рус, башкорт телләрендә басылган өч дистәгә якын китап авторы. 1977 елда «Айлы кичләр» җыентыгы һәм «Борылам да карыйм...» циклына кергән шигырьләре өчен ул Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була.

Илленче-алтмышынчы елларда Гамил Афзал күбрәк юмор-сатира жанрына игътибарын юнәлтә, «Чаян» белән актив хезмәттәшлек итә. Җитмешенче еллардан башлап аның иҗатында фәлсәфи лирика өстенлек ала башлый. Шулай ук ул юмористик һәм сатирик рухта язылган күпсанлы хикәяләре белән дә танына.

Әдипнең тууына 100 ел булуга багышлап, укучыларыбызга аның берничә шигырен тәкъдим итәбез.

МАТУРЛЫК ЭЗЛИМ

Юк, кирәкми миңа
мәрмәр сарай,
Төкермим дә алтын-көмешкә;
Миңа ипи белән катык ярый,
Миңа рәхәт шушы килеш тә.
Миңа кирәк шәфәкъ алсулыгы,
Кояш чыгыш, кояш баешы;
Миңа кирәк гөлнең иң сылуы,
Тыныч күлнең уйчан камышы.
Миңа кирәк тирән диңгез сере,
Күк читендә болыт аклыгы;
Миңа кирәк дусның эчкерсезе,
Уйнап йөргән бала шатлыгы.
Тирә-якны күзләп, атлап йөрим,
Таптап йөрим елга буйларын;
Йөрәгемә салып ятлап йөрим
Кешеләрнең якты уйларын.
Болыннарга чыгам, тау буена,
Ужым басуларын күрергә.
Мин чәчәкләр җыям ил туена,
Мин матурлык эзлим гомергә.

УРЫНБАСАР БУЛУ ЯХШЫРАК

Киңәш итәм: җәфа чигеп йөрмә,
Һөнәр эзләп йөрмә аптырап.
Яхшы гына оклад килгән җирдә
Урынбасар булу яхшырак.

Шәп кабинет. Өстәл.
Йомшак диван.
Телефонны бор да шылтырат.
Җаның тыныч булган җирдә,
туган,
Урынбасар булу яхшырак.

Бер эшне дә үзең хәл итмисең,
Берни өчен җавап бирмисең.
Эшләр хөрти китсә,
мин күрмәдем,
Мин начальник түгел бит, дисең.

Рәхәт. Җылы. Тыныч. Оклад килә.
Елына бер доклад чыгып сөйлә, –
Начальникка күрен ялтырап,
Урынбасар булу яхшырак.

ИКЕ МИН

Минем эчтә ике мин бар: берсе усал, берсе юаш,
Шул икенең берсенә дә баш булалмый гаҗиз бу баш.

Минем эчтә ике мин бар: берсе ахмак, берсе башлы,
Миңа карап, авыз ерып утыралар кара-каршы.

Минем эчтә ике мин бар: берсе чая, берсе тыйнак,
Берсе дулый давыл сорап, берсе – тыныч авыл сорап.

Минем эчтә ике мин бар, икесендә ике холык,
Икесен дә читкә этеп, үзем калам үзем булып.

МИНЕМ 100 ЕЛ ТУЛГАЧ ЯЗАЧАК ҖЫРЫМ

Күз алдымда шаулап йөз ел үтте,
Тел зиначылары үлеп бетте, –
Ялганчыга дөнья тар икән.
Күңелем һәр көн илгә бәхет көтте,
Бәхет көтеп, уй киләбен сүтте;
Эшчәннәргә бәхет бар икән,
Кичләр зәңгәр, таңнар ал икән.
Ничаклы даһилар дөньяга килде,
Ничаклы нәбиләр дөньядан китте, –
Мин һаман да эшлим, мин исән.
Көнгә карап көлеп йөргән өчен,
Кешеләргә шатлык биргән өчен,
Йөрәгем яшь, күңелем шук икән.
Әллә миңа үлем юк микән?

ТӨЛКЕ БЕЛӘН КАРГА

(Иске мәсәлнең заманча варианты)

Алла биргән сырны тешләп Карга иптәш,
Агач башына кунып бисмилла иткәч,
Күзе төште: Төлке килә биеп-биеп,
Ашау вакытын көтеп кенә йөргән кебек.

– Сандугачкай, – диде Төлке, кырын ятып, –
Сиңа хәзер операга керер вакыт,
Җырлачы, дус, дан шаулатып Европага,
Шаккатсын бер Венера Шәрипова да.

Сырны Карга тырнагына кыстырды да:
– Экономик белем хас бит безнең чорга,
Малны хәзер ычкындырмый тырнак, – диде, –
Крылов чоры үтте инде, дурак! – диде.

"КЫЗЫЛ БАЛЧЫК" АРТЕЛЕНДӘ

Бригадиры тәртип-фәлән карап тора,
Бер бухгалтер хезмәт хакын санап тора,
Бер технолог чертёж сыза, башын кашый;
Ике малай чүлмәк ясый, чүлмәк ясый.

Тәэминатчы бияләй белән тәэмин итә,
Кладовойчы чүлмәкләрне кабул итә.
Секретарь кыз боерык соңра боерык ташый,
Ике малай чүлмәк ясый, чүлмәк ясый.

Замначальник тәрәзәдән карап тора,
"Лодырьлар" дип әрләп тора, янап тора.
Начальнигы доклад яза ярсый-ярсый,
Ике малай чүлмәк ясый, чүлмәк ясый.

Артель гөрли, артель эшли, контор яза,
Бәйрәм җитә, тантаналы утырыш бара.
Начальниклар елмаешып бүләк ала,
Ике малай доклад тыңлый һәм кул чаба.





Бүген майның егерме бише. Мәктәпләрдә чыгарылыш кичәсе булырга тиешле көн...

Кәримнең лаеклы ялга чыкканына быел бер ел була, каядыр ашыгасы урыны юк, шулай да гадәттәгечә иртә тора. Күңеле белән мәктәптә булгангадыр инде. Бүген дә менә тантаналы кичәгә чакырырлар дип өметләнгән иде, тик эндәшүче булмады. Мәгариф системасында хөсетлек, көнчелек, җитәкчелеккә ялагайлык зур инде. Кәрим андый була алмады. Атнасына ничә сәгать куялар, шуңа риза булып эшләвен белде. Сыйныфындагы балаларын яратты. Алар белән эшләгәндә дөнья мәшәкатьләрен оныта торган иде. Бигрәк тә әдәбият дәресләрендә. Нинди генә темага, образлар дөньясына кереп китсәләр дә, алар өчен вакыт җитмәде. Үз предметын бик яратып эшләсә дә Кәрим, эчтән генә биология-зоология фәнен укыткан укытучыга кызыгып яшәде. Кайчан карама алар табигать кочагында булыр иде... Нинди генә экспериментлар үткәрмәсләр. Бер караганда, алар микроскоп аша икенче дөньяга кереп китәрләр, икенче караганда, тәҗрибә участогында үсентеләр тирәсендә кайнашырлар, пычрана-пычрана шуларны утырткан, су сипкән булырлар иде. Күз күне үзләре үстергән уңыштан күргәзмә оештырырлар иде. Ни әйтсәң дә образлар эчендә хыялланып утыру түгел инде. Лаеклы ялга чыгып, әйләнә-тирәне күзәтә башлагач кына күңеленә килгән фикерләр иде болар. Юк, үткән гомергә үкенмәде ул. Оныкларын мәктәпкә озаткач, Кәрим янә ишегалдына чыкты. Бакчаның аргы башыннан урап килгәндә, сыерчыкларның чыр-чу килгән тавышын ишетеп туктап калды. Сыерчык баласы оядан яртылаш чыккан да тирә-юньне күзәтә, үзе бертуктаусыз шыңшый-чәрелди. Атасымы, кайсыдыр шунда, өстәге ботакка кунып, баласын очарга өнди. Кәримгә кызык булып китте. Аның гомерендә бер тапкыр да кошларның бала очырганын күргәне юк иде әле. Шуңа да читтән генә кошларны күзәтә башлады. Апрель башларында гына җылы яклардан килгәннәр иде югыйсә, кай арада бала чыгарып, үстереп җитешкәннәр. Менә зоологияне белмәсәң, дип уйланып куйды. Ул арада теге сыерчык баласы тәвәккәлләде. Тик ерак китә алмады, куян оясы өстенә төшеп капланды. Ә ул тирәдә гел күршеләрнең бур песиләре йөри. Кәрим ярдәмгә ашыкты. Нәни кош баласын тотып алды, аның чәрелдәвенә, ычкынырга тырышып талпынуына карамастан, лапас эченнән бакча ягына алып чыкты. "Тормыш шулай башлана инде ул, кая кара дошман", – дип сөйләнә-сөйләнә кошчыкны яссы итеп ябылган түбәгә җибәрде. Моннан аналары аны бик тиз табып алырлар иде кебек аңа. Әмма кош балаларына да туганчы ук саклану инстинкты салына икән шул. Ачык урында калырга ярамаганга күрә ул шунда ук нәни канатларын җилпеп, җиргә очып төште дә юеш үлән арасына кереп югалды. Ник бер тыны чыксын. Ун-унбиш минуттан соң гына аның чәрелди-чәрелди күршеләр бакчасына кереп киткәнлеге беленде. Шунда тагын бер кызыклы фактка тап булды Кәрим. Кош баласын югарыдан, тургай кебек талпынып, чыпчык озата бара, үзе: "Балагыз менә монда, исән-сау" дигән сыман бертуктаусыз чыркырдый иде. Бу ике төрле кошның бер-берсенә ярдәм итүеме, әллә ояның аларга калуы өчен "ялагайлану" идеме, монысын алар үзләре генә белә торгандыр.

Икенче көнне дә шундыйрак хәл кабатланды. Сыерчыклар икенче балаларын очырды. Монысын да Кәрим күреп торды. Һәм янә ярдәмгә ашыкты. Юньләп оча алмаган кош баласын тотып, ачык урындагы үләнгә җибәрде дә аның шыңшый-шыңшый канатын нәҗестән арындырырга тырышуын күзәтмәкче иде. Әмма озак хисләнеп торырга туры килмәде. Күршеләрнең бакча өстеннән очып килгән тилгән күренде. Кулындагы тырмасын болгамаган булсамы... Өстенә очып килгән олы коштан Кәрим үзе дә бераз шүрләде шүрләвен, әмма сыерчык баласын тотып калырга өлгерде. Анңары аны кичә тегесе кереп югалган үлән арасына таба очырды.

Ике-өч көн үттеме микән, сыерчык оясына беркетелгән ботаклар өстендә алар дүртәү утыралар иде. Чыр-чу килеп сөйләшкәндәй италәр, ара-тирә сызгыргалап куялар. Шул ук вакытта алар Кәримне күзәтәләр дә, аңардан көләләр дә кебек иде. Боларга өстәп:

– И абзый, абзый, без үзебезнең балаларны ничек булса да үзебез карыйбыз, үстерәбез, очырабыз. Тик менә оя гына ясый белмибез. Сез шушы балалар өчен "ипотека" оештырсагыз, без сезгә янә рәхмәтле булыр идек, диялəр төсле иде.

Кәрим шул ук көнне ике сыерчык оясы ясап куйды. Тик алдагы елның апреленә чаклы тагын өч йөз кырык көн бар иде әле. Олы яшьтәгеләр өчен бу бик озын гомер шул.

Мидхәт САДЫЙКОВ



САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ

1923 елдан чыга.

№ 5 (1906) май 2021

Баш редактор:
Р. И. ХӘЛИЛУЛЛОВ
Баш рәссам: А. АЛЁШИН
Баш редактор урынбасары: Г. ЗАМАЛДЫНОВА
Үсеш бүлеге: П. СТАРОВЕРОВ
Редакторлар: Р. АБЗАЛОВ,
Л. САФИУЛЛИНА, А. ХӘМЗИН
Сайт редакторы: Л. ӘХМӘТОВА
Корреспондент: Г. СӨНГАТУЛЛИНА
Дизайнер: Л. ФӘЛӘХОВА

Учредителе һәм нәшер итүчесе «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.

420047, Казан шәһәре, Академическая урамы, 2

Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләре агентлыгы ярдәмендә оештырылган.

Журнал Роскомнадзор идарәсендә теркәлде.
Теркәлү саны һәм вакыты:
ПИ № ФС77-44364, 23 март, 2011 ел.

«Журналга «Почта России» каталогы, йә https://podpiska.pochta.ru онлайн аша язылa алалар.

Язылу индекслары:
РТ – П2438 (тат), П2440 (рус);
РФ – П7088 (тат), П7087 (рус).

Редакция материалларны авторларның ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү хокукына ия.

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» типографиясендә басылды.
Басылып чыгу: 05.05.2021 ел.
Тираж – 3417 Заказ Е-1311

Редакциянең адресы: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.

Белешмәләр өчен телефоннар:
(843) 222-06-00, 222-05-54.
E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan-journal.ru

Бәясе ирекле

16+

Уйна да, уйла да!



Ринат АБЗАЛОВ төзеде



1. Әгәр сиңа 60 яшь икән, йомгаклап нәрсә язарга була?

2. Шәфкатьле кешегә ничек өйләнергә?

3. Эшли белгәнеңне үзеңә ничек исбатларга?

4. Иҗтимагый сораштырулардагы сорауларга җавапларның барысы да дөресме?

5. Барлык кешеләрне чит телләргә өйрәтү мөмкинме?

6. Алга таба әйбәт булырмы?

7. Ни өчен ярлылар белән байларның керемнәре арасында зур аермалык?

ҖАВАПЛАР

1. "Карт ат буразнаны бозмый" дигән сүздән башлагыз. 2. Яратышып, чөнки расчет буенча өйләнү аларга кыенрак. 3. Өйләнеп. 4. Кешегә дөреслекне сөйләү – бер стакан шәраб җибәргәннән соң кулайрак. 5. Мөмкин, ләкин кирәкми, чөнки һәркемгә туган телендә сөйләшү күпкә рәхәтрәк. 6. Булыр, әмма барысына да түгел. 7. Халыкның үрчүендә гаеп: ярлылар ныграк арта, ә байлар аларны куып җитә алмый.

Сынамышларны Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА әзерләде.

Чайнвордны чишегез, номерланган шакмакларда җыр исемен укыгыз. Журналыбызның 4 нче санындагы чайнвордның тикшерү сүзе – **«КАРА КАРЛЫГАЧ МИКӘН»**

Беренче булып дөрес җавап җибәрделәр:
Г. ГАЙНЕТДИНОВА (Арча),
С. ГАЛИЕВА (Азнакай р-ны, Урманай ав.),
Р. САФИН (Балык Бистәсе р-ны, Полянка ав.),
Н. НИКИТИНА (Чистай р-ны Чуаш Ялтаны ав.),
Н. ШАКИРОВ (Казан),
Б. ШӘЙХЕТДИНОВ (Алексеевский р-ны, Урта Тигәнәле ав.),
С. ШӘЙХУЛЛИН (Казан).

Җиңүчебез – Полянкадан
Рауль САФИН!







Александр **КОСМЫЛИННЫҢ** вернисажы әзерләнгән вакытта редакциягә күңелсез хәбәр килеп иреште.

Журналга чын күңеле белән бирелгән карикатурачы вафат. Гаилә традициясен дәвам итеп, әтисе Валентин Космылин кебек, Александр да күп кенә тема һәм рәсемнәр авторы иде. Аның соңгы рәсемнәре бу вернисажда бирелгән.







4612750670080